**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7523**
**14.12.2018**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак бүлмәнең гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативы турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «2018 елның IV кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бүлмәнең гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2018 елның 12 сентябрендәге 572/пр санлы Приказы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 30 апрелендәге 289 нчы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында Яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен социаль түләүләр бирү Кагыйдәләренең 10 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яшь гаиләләргә торак сатып алуга социаль түләү күләмен исәпләү өчен, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак бүлмәнең гомуми мәйданының бер квадрат метры өчен бәя нормативын 2018 елның дүртенче кварталына 43 722 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин